КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.08.2022 Казан шәһәре № 251-П

Татарстан Республикасының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «XVIII гасыр – XX гасыр башы Бишбалта бистәсенең мәдәни катламы» җирлеге мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII гасыр – XX гасыр башы Бишбалта бистәсенең мәдәни катламы» җирлеге археологик мирас объектын әлеге боерыкка кушымта нигезендә ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
2. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары М.М.Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Н.В. Прохорова